**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Югары Чура авыл җирлеге башлыгы карары**

**11 ноябрь, 2024 ел** **№8**

**«Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Югары Чура авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 28 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә.
   Гражданнар җыенын Югары Чура авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә: Югары Чура авылы, Мәктәп ур., 34 й.

2. 2024 елның 28 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә.
   Гражданнар җыенын Югары Чура авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә: Югары Чура авылы, Мәктәп ур., 34 й.

1 Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Югары Чура авыл җирлеге Югары Чура авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

*- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;* (Югары Чура авылында

юлларны асфальтлау һәм вак таш җәеп ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(Югары Чура авылы юлларына вак таш җәю һәм аларны карап тору; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(Югары Чура авылы юлларына вак таш җәеп, чокырларны ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(Югары Чура авылы автомобиль кичүен ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(Югары Чура авылының урам юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу; машинист-тракторчы хезмәтләре; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- *тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау* (Югары Чура авылына урам яктырту өчен энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, карап тоту, яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- *су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суыртү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау* (Югары Чура авылына насослар сатып алу, урнаштыру, артезиан скважиналарын, су саклау зоналарын карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(Югары Чура авылының су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләү һәм йорт хуҗалыкларын гамәлдәге линиягә тоташтыру; проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- Югары Чура авылына су суыртү манарасы сатып алу һәм урнаштыру, Югары Чура авылы су суыртү манарасы территориясен карап тоту һәм төзекләндерү; проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- *торак пункт территориясен төзекләндерү* (Югары Чура авылында балалар һәм спорт уен мәйданчыкларын карап тоту һәм төзекләндерү; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(Югары Чура авылы урамнарында коры агачларны һәм куакларны кисү, төпләү һәм санитар эшкәртү; махсус техника яллау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүлү.

6. Югары Чура авылы башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Чура авыл җирлеге башлыгы: Р.Т. Мифтахов